БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
16 декабрь 2020 ел

**КАРАР**
№ 35

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларыннан, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары белән (2018 елның 1 ноябрендәге 152 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 11 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 3 пунктында «0,9 дан артмый» дигән сүзтезмәне «артмый торган, айлык акчалата түләүнең 0,9 күләмендә билгеләнә» дигән сүзтезмәгә алмаштырырга.

1.2. Тәртипнең 4 пунктында «0,55 тән артмый» дигән сүзтезмәне «артмый торган, айлык акчалата түләүнең 0,55 күләмендә билгеләнә» дигән сүзтезмәгә алмаштырырга.

1.3. Тәртипнең 5 пунктында «0,55 тән артмый» дигән сүзтезмәне «артмый торган, айлык акчалата түләүнең 0,55 күләмендә билгеләнә» дигән сүзтезмәгә алмаштырырга.

1.4. Тәртипнең 7 пунктында «0,6 дан артмый» дигән сүзтезмәне «артмый торган, айлык акчалата тулаем хезмәт хакының (содержаниенең) 0,6 күләмендә билгеләнә» дигән сүзтезмәгә алмаштырырга.

2. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин